**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2017 Балык Бистәсе штп. № 266пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында "Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 12 декабрендәге 3253-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 12 декабрендәге 286/2-пр номерлы боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлап алу турындагы Нигезләмә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу тәртибен расларга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында "Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу буенча ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын №2 кушымта нигезендә расларга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 15 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары И. Р. Хисмәтовага йөкләргә.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017 елның 19 декабрендәге
266пи номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында “Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу тәртибе**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу тәртибе (алга таба– Тәртип) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 12.12.2017 ел, №286/2-пр боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлап алу турындагы нигезләмәнең 3.2 пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу тәртибен (алга таба – башлангыч сайлап алу) билгели.

1.2.Алдан сайлап алуны үткәрүнең максаты –2017 елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча кертелгән электрон хуҗалык кенәгәсендә язылу нигезендә,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча иң күп мөгезле эре терлек, шул исәптән 50% тан да ким булмаган савым сыерлары асрый торган шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын (алга таба-шәхси ярдәмче хуҗалыклар) билгеләү.

1.3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алуны уздыру буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оештырыла торган ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) алдан сайлап алуны оештыра.

1.4.Алдан сайлап алу комиссиясе тарафыннан 2017 елның 20 декабренә кадәр үткәрелә.

1.5. Алдан сайлап алуны уздыру сроклары, шартлары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) (алга таба – Идарә) тарафыннан , «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр»

бүлегендә  шәхси ярдәмче хуҗалык башлыкларын «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә республика сайлап алуын уздыру сроклары һәм шартлары турында мәгълүмат урнаштырганнан соң, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләренә җиткерелә

1.6.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 12 декабрендәге 3253-р номерлы күрсәтмәсенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыннан бер җиңүче билгеләнә. Алга таба алдан сайлап алу җиңүчесе Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 12.12.2017 ел, №286/2-пр боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлап алу турындагы Нигезләмәнең 1.6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан 100,0 мең сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә.

2.Алдан сайлап алуда катнашучылар

2.1. Алдан сайлап алуда түбәндәге таләпләргә туры килә торган шәхси ярдәмче хуҗалык башлыкларына катнашу рөхсәт ителә :

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы агымдагы ел дәвамында крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан оештырылган ведомство программалары буенча грант алучы булып тормый;

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы «Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» номинациясендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарында авыл халкының эшлекле активлыгына йомгак ясау буенча зона семинар-киңәшмәләре кысаларында ел саен уздырыла торган республика конкурсы йомгаклары буенча субсидия алмый.

2.2.Беренчел сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы Идарәгә 2017 елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча түбәндәге документларны тапшыра:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 12 декабрендәге 286/2-пр номерлы боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлап алу турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгына акчалата премия тапшыру өчен  гариза;

электрон хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

номинантның шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 12.12.2017 ел, №286/2-пр боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлавы турындагы Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Әлеге пунктта күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырыла.

2.3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 12 декабрендәге 286/2-пр номерлы боерыгы

белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлавы турындагы Нигезләмәнең кушымтасында билгеләнгән формада төзелмәгән очракта, алар әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән срокны бозып яисә тулы күләмдә тапшырылмаса, документларны кабул итүдән баш тартыла.

3. Алдан сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Идарәгә кергән документлар әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә комиссия тарафыннан карала.

3.2.Комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә. Комиссия составына рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары керә.

3.3. Комиссия эше белән комиссия рәисе җитәкчелек итә. Ул булмаганда, рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасарына йөклиләр.

3.4. Комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан һәм вазыйфаи затлардан Комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләре, вазыйфаи затларын һәм башка вәкилләрен, шулай ук Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен башка затларны чакырырга.

3.5. Әлеге Тәртипнең 1.2, 1.6, һәм 2.1 пунктлары таләпләрен исәпкә алып, Комиссия 2017 елның 20 декабренә кадәр бүләкләүгә кандидатны алдан сайлап ала һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 12 декабрендәге 286/2-пр номерлы боерыгы белән расланган «Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык» исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын республика сайлап алу турындагы Нигезләмәнең 2.2 пункты таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына документлар пакетын тапшыра.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017 елның 19 декабрендәге
266пи номерлы карарына 2
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында "Иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" исеменә шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларын алдан сайлап алу буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Хисмәтов Ильшат Рафхат улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Мингалиев Марат Зиннур улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Мөхәммәтшин Рафаэль Рахимҗан улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Гатиятов Делюс Харис улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Ибраһимова Резеда Габделхәй кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы урынбасары |